Республика Татарстан
Глава
Ильбяковского сельского поселения
Азнакаевского муниципального района

Татарстан Республикасы
Азнакай муниципаль районы
Илбәк авыл җирлеге
башлыгы

ул. А.Валеева, д. 53, село Ильбяково,
Азнакаевский район, 423321

Ә.Вәлиев урамы, 53нче йорт, Илбәк авылы,
Азнакай районы, 423321

Тел. (факс) 8(85592) 38-5-38; e-mail: Ilb.Azn@tatar.ru;
http://aznakayevo.tatarstan.ru/

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«02» ноябрь 2020 ел №6

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Илбәк торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын үткәрү турында

2003 елның 06 октябрендәге №131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге №45-ТРЗ «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Уставы нигезендә, **карар чыгарам:**

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Илбәк торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены 2020 елның 14 ноябренә билгеләргә.

1.2. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Илбәк торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы – Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Башкарма комитеты;

- гражданнар җыенын үткәрү вакыты – 2020 елның 14 ноябре 10.00 сәг тән 11.00 сәг кә кадәр;

- үткәрү урыны – Илбәк авылы, балалар уен мәйданчыгы торриториясе дип билгеләргә.

1.3. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

- 2020 елның 03 ноябреннән дә соңга калмыйча гражданнарга Илбәк авылы, Ә.Вәлиев урамы, 50 йорт адресы буенча урнашкан, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Башкарма комитетында һәм Илбәк авылы, Ә.Вәлиев ур, 10а адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендында гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын бирергә;

- Илбәк торак пунктында сайлау хокукына ия булган яшәүчеләр исемлеген төзергә;

- гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерләргә;

- массакүләм мәгълүмат чараларында һәм башка ысуллар белән Илбәк торак пункты халкына гражданнарның җыены турында хәбәр итәргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2021 елда 1төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, Илбәк авыл җирлеге Илбәк торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә, 2 төркем инвалидларыннан, 80 яшьтән өлкән пенсионерлардан, күп балалы гаиләләрдән бер тапкыр түләтүне 150 сумга киметеп, үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- җирлек территорияләрен төзекләндерүне оештыру (ике телдә урам исемнәре язылган күрсәткечләр һәм торак йортлар өчен номерлар әзерләү/сатып алу, триммер һәм триммер өчен запас частьләр сатып алу);
- Илбәк авылы җирлегенең урам утларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампалар, яктырткычлар, электр товарлары һәм махсус җиһазлар сатып алу, алмаштыру, урам утларын ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү);
- бәйрәм чараларын оештыру һәм үткәрү («Җиңү көне»,«Сабантуй», «Өлкәннәр көне»,«Яңа ел» бәйрәмнәрен үткәрү өчен бүләкләр һәм сувенир продукциясе сатып алу, бәйрәм чараларын үткәрү өчен килешү буенча хезмәт күрсәтү;
- Илбәк авылындагы юлларны кардан чистарту (килешү буенча түләү).

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталы»нда түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru һәм Илбәк авылы, Ә.Вәлиев урамы, 10а йорт; Илбәк авылы, Ә.Вәлиев урамы, 50 йорт адреслары буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

4. Әлеге карар ул халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Башлык Л.Р.Әсәдуллина